**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г. Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2024 елның 5 августы** **62-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясен төзү турында»2022 елның 28 мартындагы 29-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм комиссия эшчәнлеген камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясен төзү турында» 2022 елның 28 мартындагы 29-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына (2023елның23 октябрендәге 113-РС номерлы соңгы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм комиссия әгъзасы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федорина Екатерина Петровна - Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы (килешү буенча)»

2) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе әгъзасы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федорина Екатерина Петровна - Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча)».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы урынбасары - Совет рәисе урынбасары Т. П. Борһановага йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**